| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Терсинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Тирсә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.04.2021 Тирсә авылы № 10-1

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына тапшырырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү һәм Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге башкарма комитетына җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында килешү төзергә.
4. Әлеге карарны Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

(https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 21 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе И. Б. Гыйззәтуллин